РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт

тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
16.09.2022

КАРАР
№23

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге чикләрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитетының 19.08.2016 ел, №32 карары белән расланган янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 21.12.1994 ел, №69-ФЗ Федераль закон һәм «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» Федераль законына үзгәрешләр кертү хакында» 14.07.2022 ел, №276-ФЗ Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турындагы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында» 2016 елның 19 августында 32 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 нче пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чарасы булып янгын сүндерүне оештыру буенча чаралар комплексының бер өлеше булган янгыннарны булдырмау, кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннардан коткару буенча билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән нормаларны һәм кагыйдәләрне тормышка ашыру тора.

1.2. 6.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итүгә керә:

1) су челтәрендә урнаштырылган янгын гидрантлары белән үзәкләштерелгән һәм (яки) үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү системалары (янгынга каршы тышкы сууткәргеч);

2) Россия Федерациясе законнары нигезендә янгын сүндерү максатларында кулланыла торган су объектлары;

3) янгын сусаклагычлары.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/artash адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арташ авыл
җирлеге башлыгы

А.Р.Әгъләмҗанов